# КАРАР

**23 ноябрь 2021 ел** **N 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 8 - 23 ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыеннары беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру;

-Арча шәһәренең түбәндәге урамнарына нигез һәм өслек җәю, гамәлдәге капламның өске катламына вак таш түшәү:

Хезмәт ур. (44 йорттан 62 йортка кадәр); Вокзал ур. (тимер юл вокзалыннан 59 йортка кадәр); Вокзал ур. (8 -48 йортлар); Җиңү ур.; Салихов ур. ( - йортлар); Наратлы ур. (1 -7 йортлар); Күл ур.; Урман ур. 1 нче тыкрык, Урман ур. 3 нче тыкрык, Урман ур.; Елга аръягы ур.; Елга аръягы урамыннан Татарстан урамына кадәрге квартал; Бирәзә тыкрыгы; Кояшлы урамнан Хезмәт урамына кадәрге квартал; Җиңү урамыннан Вокзал урамына кадәрге квартал.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, җирлек башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Җыен беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә:

җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегендә 15822 кеше, гражданнар җыенында тавыш бирүдә 8448 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары

түбәндәгечә бүленде:

жыенда катнашкан 5744 кеше "Әйе" позициясе өчен тавыш бирде; 2704 кеше "Каршы" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар жыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнар жыенын узган, гражданнар жыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру;

-Арча шәһәренең түбәндәге урамнарына нигез һәм өслек җәю, гамәлдәге капламның өске катламына вак таш түшәү:

Хезмәт ур. (44 йорттан 62 йортка кадәр); Вокзал ур. (тимер юл вокзалыннан 59 йортка кадәр); Вокзал ур. (8 -48 йортлар); Җиңү ур.; Салихов ур. ( - йортлар); Наратлы ур. (1 -7 йортлар); Күл ур.; Урман ур. 1 нче тыкрык, Урман ур. 3 нче тыкрык, Урман ур.; Елга аръягы ур.; Елга аръягы урамыннан Татарстан урамына кадәрге квартал; Бирәзә тыкрыгы; Кояшлы урамнан Хезмәт урамына кадәрге квартал; Җиңү урамыннан Вокзал урамына кадәрге квартал.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, җирлек башкарма комитетына акчаны жыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт; Арча шәһәре, Һ. Такташ ур., 58 йорт; Арча шәһәре, Өрәңгеле ур., 4 йорт; Арча шәһәре, Банк ур., 2А йорты адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында, интернет-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы И.Г.Нуриев